ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документлар рәвешендә төзүченең һәм проект декларациясенең Федераль законның 3 статьясындагы $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә йә мондый бәяләмә бирүдән дәлилләнгән баш тарту турында документ бирү;»;

2) егерме дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип таныргa;

3) утыз дүртенче абзацта «торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасыннан» сүзләрен «торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) утыз җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йортның һәм (яисә) башка күчемсез мөлкәт объектының (төзелеш проектының) әзерлек дәрәҗәсе һәм Федераль законның $15^4$ статьясында каралган счетларны кулланмыйча гына өлешле төзелештә катнашу шартнамәләрен төзү мөмкинлеге булу турында бәяләмәне (алга таба – критерийларга туры килү турында тикшереп тору органы бәяләмәсе) бирү, критерийларга туры килү турында тикшереп тору органы бәяләмәсен бирү хакында гаризаны, критерийларга туры килү турында тикшереп тору органы бәяләмәсен яисә критерийларга туры килү турында тикшереп тору органы бәяләмәсен бирүдән баш тарту хакында документны, тиешле карар кабул ителгән көннән соңгы өч эш көненнән дә соңга калмыйча, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына урнаштыру;»;

5) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен төзүчеләргә кагылышлы кирәкле мәгълүматны вәкаләтле банктан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясенең Үзәк банкы белән килештереп билгеләнгән тәртиптә соратып алуны гамәлгә ашыру.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 16 октябрь
№ 79-ТРЗ